**Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**10-11 нче сыйныф**

**Эш вакыты – 120 минут**
**Гомуми балл – 100**

**1. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз. Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 3 балл.**

**1.1. Кайсы фәлсәфәче беренче булып җәмгыятькә карата “система”, “институт”, “структура” төшенчәләрен куллана.**

а) О.Конт

б) Г.Спенсер

в) Ж.Ж.Руссо

г) А.Смит

**1.2. Түбәндәге сәяси партияләрнең кайсысы 1993 елдан 2021 елга кадәр даими рәвештә РФ Дәүләт Думасының барлык сайлауларында катнашты?**

а) Аграр партия

б) Гадел Россия

в) ЛДПР

г) Пенсионерлар партиясе

**1.3. 2026 елда Татарстанда М.Ш.Шаймиевны беренче президент итеп сайлауга ничә ел була?**

а) 25

б) 30

в) 35

г) 20

**2. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 7 балл.**

**2.1. Икътисади цикл эзлекле төстә бер-берсен алмаштыручы дүрт фазадан тора. Шул дүрт фазаны атагыз:**

Җавап:___________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**2.2. Ихтыяҗ – ул кеше тарафыннан аның организмын яшәтү һәм шәхесен үстерү өчен кирәкле нәрсә турында кичерелгән һәм аңланган мохтаҗлык. Җәмгыять белемендә кешенең ихтыяҗларын өч төркемгә бүлеп карау каралган. Бу өч төрле ихтыяҗны атагыз:**

Җавап:___________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**3. Сорауларны укыгыз һәм биремнәрне башкарыгыз. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 4 балл.**

**3.1. Түбәндә китерелгән юридик затлар төрләре өчен гомумиләштерүче терминны күрсәтегез:**

Хуҗалык ширкәтләре; хуҗалык җәмгыятьләре; крестьян (фермер) хуҗалыклары; хуҗалык партнерлыклары; җитештерү кооперативлары; дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр.

А) Корпоратив юридик затлар

Б) Коммерция юридик затлар

В) Унитар юридик затлар

Г) Коммерция булмаган юридик затлар

Җавап:___________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**3.2. Түбәндә фискаль (бюджет-салым) һәм монетар (акчалата-кредит) сәясәт чаралары күрсәтелгән. Монетар (акчалата) сәясәткә караган барлык мисалларны күрсәтегез.**

А) X дәүләте НДФЛ (физик затлар керемнәренә салым) ставкасын 13 проценттан 15 кадәр арттырды

Б) G дәүләте укытучыларның хезмәт хакын 20% ка арттырды

В) А дәүләте банкларны үз капиталының 10% ын махсус счетларда резервларга мәҗбүр итте

Г) К иленең Үзәк банкы исәпкә алу ставкасын 10% тан 14% ка кадәр күтәрде

Д) Т дәүләте мәгарифкә чыгымнарны 3% ка киметү карарын кабул итте

Җавап:____________________________________________________________________

**4. Бирелгән таблица күрсәткечләрен анализлагыз. Әгәр 2025 ел нәтиҗәләре буенча Россиядә инфляциянең 3% тәшкил иткәнлеге билгеле булса, 2025 елда чын тулай региональ продукт (ВРП) кайсы регионнарда артканың билгеләгез. Дөрес җавап өчен 6 балл.**

| РФ регионнары | ВРП 2024 (млрд. руб) | ВРП 2025 (млрд. руб) |
|---|---|---|
| А) Курган өлкәсе | 215,6 | 233,5 |
| Б) Свердловск өлкәсе | 2423,7 | 2529,5 |
| В) Ханты-Мансийск автоном өлкәсе-Югра | 4506,7 | 4563,1 |
| Г) Татарстан | 3051,6 | 3100,6 |
| Д) Төмән өлкәсе | 1316,7 | 1255,5 |
| Е) Челябе өлкәсе | 1521,3 | 1545,6 |

Җавап:____________________________________________________________________

**5. Сорауга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә “<u>әйе”</u>, туры килмәгәндә, “<u>юк”,</u> дип билгеләгез. Җавабыгызны таблицага языгыз (Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 6 балл).**

5.1. Куллanучылар кредиты ставкасын төшерү, инфляция темпларының кимүенә китерәчәк.

5.2. Эш бирүче, хезмәткәр ризалыгыннан башка хезмәт килешүен өзә алмый.

5.3. Икътисадый җитештерүне автоматлаштыру индустриаль җәмгыять өчен хас.

5.4. Компьютер технологияләрен, интернет челтәрен үстерү постиндустриаль җәмгыятьтә бара.

5.5. Түбән социаль мобильлек - индустриаль җәмгыять үзенчәлеге.

5.6. Гади хезмәт коралларыннан файдалану традицион җәмгыять өчен хас.

Җавап:

| **5.1.** | **5.2.** | **5.3.** | **5.4.** | **5.5.** | **5.6.** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**6. Биремне укыгыз һәм сорауга җавап бирегез. 10 балл.**

Н. предприятиесе бухгалтерына ай ахырында мебель җитештерү буенча предприятиенең чыгымнарын исәпләргә кирәк. Ул аларны түбәндә китерелгән таблицага язып куйды. Узган айда **үзгәрүчән чыгымнар күләмен** (переменные издержки) һәм **даими чыгымнар** (постоянные издержки) күләмен санап чыгарыгыз:

| Чыгымнар | Бер ай өчен бәя |
|---|---|
| Реклама | 50000 |
| Чыгым материаллары | 110000 |
| Бинаны арендлау | 30000 |
| Эшчеләрнең эш хакы | 230000 |
| Амортизация | 70000 |
| Электр энергиясе | 7000 |
| Эш хакының бонус өлеше | 50000 |

**Җавап:**

Үзгәрүчән: ___________________

Даими: ___________________________

**7. Илләр һәм аларда идарә һәм дәүләт төзелеше формалары арасындагы тәңгәллекне туры китерегез:**

**Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

| Илләр | Идарә һәм дәүләт төзелеше формалары |
|---|---|
| 1) Армения | А) Парламент республикасы + унитар дәүләт |
| 2) Нидерланды | Б) Конституцион монархия + унитар дәүләт |
| 3) Көньяк Корея | В) Президент республикасы + унитар дәүләт |
| 4) Австрия | Г) Парламент республикасы + федерация |
| 5) Мексика | Д) Президент республикасы + федерация |

**Җавап:**

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**8. Түбәндәге ситуацияне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз. Дөрес һәм тулы җавап өчен 9 балл.**

Юридик консультациягә ирле-хатынлы Каримовлар мөрәҗәгать итте һәм түбәндәгене хәбәр итте. Аларның улы Нияз бер ел элек фаҗигале рәвештә үлде. Аның хатыны, биш яшьлек кызын үзе белән алып, башка шәһәргә күчеп китә һәм яңадан кияүгә чыга. Аның яңа ире кызны кызлыкка алган. Каримовлар оныгын бик сагына һәм аның янына килергә тели, әмма оныгы белән очрашуны таләп итәргә хаклары бармы-юкмы икәнен белмиләр. Аларга нинди киңәш бирергә була?

Җавап:_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

**9. Татарстан Республикасы конституциясеннән өзекләрне укыгыз һәм буш (сан белән күрсәтелгән) урыннарны тутырыгыз. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 20 балл.**

Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе составындагы (1_______) хокукый дәүләт.

Татарстан Республикасында хакимият аның (2 __________) тарафыннан турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында дәүләт телләре – тигез хокуклы (3 _____) һәм (4 _______) телләре.

Халык хакимиятенең иң югары турыдан-туры чагылышы – (5_________) һәм ирекле сайлаулар.

Дини берләшмәләр дәүләттән (6 ________) һәм закон каршында тигез.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы – Татарстан Республикасы парламенты – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең даими эшләүче вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару органы. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (7 _____) елга сайлана.

Татарстан Республикасы (8 ______) дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була. Закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы сайланырга мөмкин.

Татарстан Республикасында хөкем итү бары тик (9 ______) тарафыннан гына гамәлгә ашырыла

Татарстан Республикасының (10_________), Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны – Татарстан Республикасы дәүләтчелеген, Татарстанның күпмилләтле халкы үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдыручы рәсми символлары бар.

Җавап:

| | |
|---|---|
| 1. | |
| 2. | |
| 3. | |
| 4. | |
| 5. | |
| 6. | |
| 7. | |
| 8. | |
| 9. | |
| 10. | |

**10. Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез. Барлыгы 12 балл.**

**Дәүләт базар икътисады шартларында**

Икътисадның барлык агентларын илнең бердәм базар тирәлеге (пространствосы) берләштерә, анда барысы өчен дә бертөрле булган уен кагыйдәләрен дәүләт институтлары күзәтеп торалар һәм ярдәм күрсәтәләр... Базар үзе генә конкурентлыкны тотып торырга сәләтсез. Икътисад өлкәсендә конкурентлыкны саклап калу һәм стимуллаштыру – дәүләт функциясе. Монополия белән көрәшеп, конкурентлыкны саклап калып, дәүләт шулай ук, базар системасының гомумән тотрыклылыгын гарантияләп, базар моделе чикләрендә, һәм аннан тышта тора. Тотрыклылыкны саклау конкурентлыкны саклаудан кимрәк роль уйнамый. Илдә уңай социаль климат, финанс системасының ныклыгы, аеруча хезмәт күрсәтү өлкәсендә иҗтимагый байлыклар җитештерүне киңәйтү тиешле дәүләт институтларының ышанычлы, актив роленә бәйле... Шуңа күрә хәтта теоретик базар моделендә дә дәүләткә мөһим роль бүленгән – гомуми, яисә иҗтимагый мәнфәгатьләрне чагылдыру юлы белән базар системасын саклап калу. Бер генә шәхси бизнес та, нинди генә гигант дәрәҗәләргә ирешмәсен, табигате белән үзенең шәхси мәнфәгатьләрен читкә кагып, җәмгыять мәнфәгатьләрен үз җилкәсенә аудара алмый. Әмма мондый вазифалар белән дәүләт шул демократик җәмгыятьнең бер өлеше булган очракта гына шөгыльләнә ала. Мондый җәмгыятьтә базар механизмнары белән беррәттән, сайлаучыларның дәүләт аппараты өстеннән күзәтчелек итүенең демократик механизмнары да җайга салынган, ә суд системасы законга бәйле рәвештә барлык гражданнарның хокукый яклануын тәэмин итә.

(А. Пороховский)

1. Текстта базар икътисадында дәүләтнең нинди өч икътисади функциясе аталган? (3 балл)

Җавап:____________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

2. Автор җәмгыять тормышының дәүләтнең алар белән идарә итүдә актив роленә бәйле булган социаль-икътисади күренешләрен санап китә. Аларның теләсә кайсы өчесен атагыз һәм берсен үрнәк белән тасвирлагыз (3 балл).

Җавап:______________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

3. Документ авторы дәүләтнең конкуренцияне саклап калу һәм үстерүдәге ролен ассызыклый. Җәмгыять белеме курсыннан алган белемнәрегезгә таянып, конкуренциянең базар икътисады өчен әһәмиятлелеген раслаучы өч факт китерегез (3 балл).

Җавап:______________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

4. Базар икътисады һәм демократиянең бәйлелеге мәсьәләләре буенча төрле карашлар әйтелә. Автор нинди позициядә тора? Ул китергән ике дәлилне атагыз һәм аларның теләсә кайсын мисал китереп аңлатып бирегез (3 балл).

Җавап:______________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**11. Татар халкының күренекле шәхесләренең исемнәрен атагыз һәм алырның татар дөньясына керткән өлешләрен кыскача билгеләгез. Дөрес исем өчен 3 балл. Керткән өлешләрен атау өчен 3 балл. Барлыгы 18 балл.**

**1.**



**2.**



**3.**



Җавап: